МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.05.2015 г.Казань № 96/2-пр

**О внесении изменений в Приказ Министерства от 15.01.2015 № 3/2-пр «Об утверждении порядков предоставления субсидий за счёт средств, поступающих из федерального бюджета на государственную поддержку агропромышленного комплекса Республики Татарстан на 2015 год»**

Во исполнение Федерального закона от 01.12.2014 № 384-ФЗ «О федеральном бюджете на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов» (ред. от 20.04.2015),

п р и к а з ы в а ю:

1. Внести в приказ Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан от 15.01.2015 № 3/2-пр «Об утверждении порядков предоставления субсидий за счёт средств, поступающих из федерального бюджета на государственную поддержку агропромышленного комплекса Республики Татарстан на 2015 год» (ред. от 12.03.2015 № 36/2-пр) (далее - Приказ) следующие изменения:

Пункт 5 приложения № 1 к Приказу изложить в следующей редакции:

«Объём субсидий для сельскохозяйственных товаропроизводителей рассчитывается на 1 гектар посевной площади по следующей формуле:

V=П x (216,0 + (3,65 x У)+(72,0 x Иппмр)),

где:

V – объём субсидий к перечислению, рублей;

П – посевная площадь в гектарах, которая подтверждена информацией о фактических посевных площадях, на основании которой формируется официальная статистическая отчётность об уборке урожая за 2014 год (далее – информация об уборке урожая);

216,0 – минимальная ставка на гектар посевной площади, рублей;

3,65 – ставка на 1 центнер производства зерновых единиц, рублей;

У – средняя урожайность сельскохозяйственных культур, выраженная в центнерах зерновых единиц, произведённых с одного гектара посевов на основании информации об уборке урожая за 2014 год в соответствии с Приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 11 января 2013 года № 6 «Об утверждении коэффициентов перевода в зерновые единицы сельскохозяйственных культур»;

72,0 – средняя ставка на гектар посевов по плодородию земель, рублей;

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ
МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
"20" 05 2015 г.
РЕГИСТРАЦИОННЫЙ № 2730

Иппмр – средневзвешенный индекс почвенного плодородия по муниципальному району Республики Татарстан, определённый в соответствии с методикой, утверждённой Приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 11 января 2013 года № 5 «Об утверждении Методики расчёта показателя почвенного плодородия в субъекте Российской Федерации», на основании данных, предоставленных Федеральным государственным бюджетным учреждением «Центр агрохимической службы «Татарский» и Федеральным государственным бюджетным учреждением «Станция Агрохимической службы «Альметьевская» (далее – агрохимслужбы) в соответствии с приложением к настоящему порядку».

2. Контроль за исполнением Приказа возложить на первого заместителя министра Н.Л. Титова.

Заместитель Премьер – министра
Республики Татарстан – министр М.Г. Ахметов

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.05.2015 г.Казань № 96/2-пр.

Министрлыкның “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына федераль бюджет турында” 2014 елның 1 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законны (2015 елның 20 апрелендәге редакциядә) үтәү очен,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (2015 елның 12 мартындагы 36/2-пр номерлы боерык редакциясендә) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкка 1 нче кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен 1 гектар чәчү мәйданына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

V=П х (216,0 + (3,65 х У)+(72,0 х Иппмр)),

монда:

V – күчерелә торган субсидияләрнең күләме, сум;

П – гектарларда исәпләнгән чәчү мәйданы, ул факттагы чәчүлекләр мәйданнары турындагы мәгълүмат белән дәлилләнә, мәгълүмат нигезендә исә 2014 ел уңышын җыеп алу турында рәсми статистик хисап төзелә (алга таба – уңыш җыеп алу турында мәгълүмат);

216,0 – бер гектар чәчүлек мәйданына минималь ставка, сум;

3,65 – ашлык берәмлекләрен җитештерүнең 1 центнерына ставка, сум;

У – авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, ул Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә 2014 елга уңыш җыеп алу турында мәгълүматка нигезләнеп бер гектар чәчүлектән алынган ашлык берәмлекләре центнерларында күрсәтелә;

72,0 – чәчүлекнең бер гектарына жирләрнец уңдырышлылыгы буенча уртача ставка, сум;

Иппмр – Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача алынган индексы, ул әлеге тәртипкә кушымта нигезендә “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия станциясе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – агрохимия хезмәтләре) тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга нигезләнеп Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика нигезендә билгеләнә.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов